Көлү – сихәт, көлеп яшәү мәслихәт!

ISSN 0136-7110

ЧАЯН



САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ АПРЕЛЬ * 2024 * КАЗАН

4



Александр ШУЛЬПИНОВ

Алмаз ХӘМЗИН

ЯШӘСӘҢ – ЯШӘ ИКӘН УЛ!

Сайрасаң, сайра икән ул
Талда былбыллар кебек.
Җырласаң, җырла икән ул
Илдә Илһамнар кебек!

Атсаң ат икән таң булып,
Җиһанны ямьләндереп.
Җиңсәң җиң икән дошманны
Муса Җәлилләр кебек!

Тусаң ту икән дөньяга
Кирәклегеңне белеп.
Данла яклап гаделлекне
Тукай, Такташлар кебек!

Биесәң бие икән ул –
Булырлык шаккатырга!
Тагын бер шәп Нуриевы
Бар, дисеннәр, татарда!

Язсаң яз икән җырларны
Халкың җырларлык итеп.
Сүзләреңнән тамсын мәгънә,
Көйдән торсын наз бөркеп, –
Нәкъ Сәйдәшнеке кебек!

Уйнасаң уйна театр,
Төшенеп кирәклеген.
Тинчуриннар кебек җиткер
Халкың таләбен бүген.


Булсаң бул түрә иң күркәм,
Күркә булма тәхеттә.
Мена шул җитми алардан
Бездәйләргә, бәхеткә.

Татар булсаң бул икән ул
Хаклык өчен үләрлек!
Академик Нигъмәтуллин
Кебек мөнбәр төярлек!

Үрнәк алыр затлар күп ул
Татарларда, теләсәң...
Чын даһие булырсың шәт,
Сатылмыйча яшәсәң!..

Алар бары теләгәннәр
Матур тормыш корырга.
Безгә дә бит күптән кирәк
Шулар кебек булырга!

Михаил ЛАРИЧЕВ



ШОМБАЙ *болай диде...*



Хөрмәтле Чаян! Кайчагында, кызыксынып, астрологик фаразлар укыштыргалыйм. Ниләр генә вәгъдә итмиләр алар миңа! Ләкин, шуңа да карамастан, эштә берничек тә карьера ясап булмый, офыкта бай кияү дә күренми әле, язмыш та вәгъдә иткән күңелле бүләкләр ясарга ашыкмый. Югыйсә йолдызнамәнең иң шәп билгеләренең берсе астында туганмын бит...

Р. СӘЕТОВА.

КАЗАН.

– Барысы да дөрес, – диде Шомбай ага, укучыбызның хатын укып чыккач. – **Бездә язмышны кайчан тууың түгел, ә кемдә тууың билгели шул.**

ЮККА ӘЙТМӘСЛӘР...

Кызларга ошар өчен, акыллы, чибәр, бай йә мәче булырга кирәк.

Соңарып кайткач, хатынызгыз елмаеп каршы ала икән, димәк, сез чит фатирга эләккәнсез.

Әгәр гашыйк буласың икән, ул хатын белән хатынының күзенә күренергә оят булмаслык булсын.

Хатын-кызның үз-үзен яратуының чиге юк! Аңа сөелү генә аз, ул әле бердәнбер булырга да тели...

Хатын ирдән бер генә нәрсә тели – барысын да.

(Хатын-кыз белгечләре мәҗлесендә язып алынды).

• • •

Яз килде. Тамчы тама башлады.


Идарәче компаниянең директоры урамгы чыкты.

Түбәдән өзелеп төшкән боз сөңгесе аның башына төште.

Травмпункт табибы травманың сәбәбе турындагы графага ничек язарга дип уйга калды. Аннан, елмаеп, «Яз килде...» дип язып куйды.

Сергей КОКАРЕВ





Сергей АНДРИАНОВ

Өч хәрефлек белем

Дөньяда иң шәп булып саналган безнең мәктәп белеменә бәя бирү тәртибен өч хәрефтән торган безнең өчен ят системага күчерүгә инде ике дистә ел узды. Тик "тормышның төп сынавы" урынын алган Бердәм Дәүләт Имтиханы тирәсендә бәхәсләр һаман да тынмый. Башкача булуы мөмкин дә түгел, чөнки ун ел укуның нәтиҗәсен мондый формада билгеләүнең кирәклеген гражданнарның күбесе кабул итә алмый.

БДИны яклаучыларның үз дәлилләре бар: хәзерге сораулар предметның бөтен якларына да кагылган булса, ә элеккеге – гадәти имтиханда исә билетта ике генә сорау куела иде. Әгәр бәхетең елмаеп, шуларны гына белсәң дә, "бишле" кесәңдә иде. Ә бүгенге мәктәпне тәмамлаучылар фәнне төпләп өйрәнүнең кирәк түгеллеген белеп тора. Иң әһәмиятлесе – еш очрый торган сорауларны ятлап чыгарга, әгәр инде башың бөтенләй буш икән, җавапны бармак белән төртеп бирергә була. Кем белә бит — бәлки туры килер!

БДИ файдасына тагын бер аргумент – ул вузларга керү сынауларында котырып чәчәк аткан коррупцияне кысу. Әйе, бу шулай. Ректор кесәләренә гөрләп аккан акча ташкыннары бераз саеккандыр, әмма бөтенләй юкка чыкмаган. Акча, физикадагы энергия шикелле, беркая да китми, бары тик формасын гына үзгәртә. Бу очракта исә ул өстәмә рәвештә эшләүче укытучылар һәм репетиторларга күчә.

Һәм, ниһаять, "өч хәреф"не яклаучыларның төп дәлиле. БДИ буенча яхшы баллар һәм компьютер тычканының җиңел хәрәкәте нәтиҗәсендә әллә нинди ерак авылда мәктәп тәмамлаган егет йә кыз илнең теләсә кайсы уку йортының студенты булып китә ала. Ярый, монысы да булды ди. Ләкин элек вуз профессорлары белемгә сусаган яшүсмерләргә белем буенча гына түгел, ә шәхси сыйфатлар буенча да бәя биргән булсалар, хәзер дә, карбызны ярып карамыйча белеп булмаган кебек, абитуриентларны да ничек бар, шулай кабул итәргә туры килә.

Ә реформалар белән мәгариф тәҗрибәләре куышлы уйнаган арада бичара укучыларга, БДИны бөкләп салу өчен, тере укытучыны түгел, ә җансыз системаны алдарга тырышырга туры килә.

Берзаман Казанда бер 11 нче сыйныф укучысы имтиханга гипсланган кул белән килгән. Күзәтүчеләр, аны жәлләп, телләрен шартлатканнар, тик кинәт кенә гипс эченнән шалтырау тавышы ишетелгән – аның эчендә мобиль телефон яшерелгән булган. Егет шпаргалкалар әзерләп интекмәскә булган һәм шушы юлны сайлаган. Кызганыч, барып чыкмаган...

Менә Карачай-Чиркәстә имтиханга улы урынына әтисе килгән. Экзаменаторлар моны тиз генә аңлый алмаганнар. Башта үз яшеннән өлкәнрәк күренүче укучыны җентекләп күзәткәннәр. Ә аннан соң аның йөзен паспорттагы фото белән чагыштыргач, ялган ачыкланган. Атага имтиханны ташлап китәргә туры килгән.


Әйтергә кирәк, мәктәпне тәмамлаучыларның әти-әниләренә кайчандыр алынган белемнәрен легаль рәвештә дә тикшерергә була. Инде берничә ел өлкән буын өчен БДИ каршында куркуны киметергә тиешле "Бергә тапшырабыз" дип аталган Бөтенроссия акциясе эшләп килә. Өлкәннәр онлайнда күңел ачып утырган арада, балалар үзләренең киләчәк тормышын билгеләүче, әлеге дә баягы, өч хәреф өстендә баш вата. Кеше турында БДИ буенча фикер йөртмиләр, дип сөйләсәләр дә, тормышта башкачарак килеп чыга.

Людмила САФИУЛЛИНА



Игорь КИЙКО

Михаил ЛАРИЧЕВ





Вячеслав ШИЛОВ



Виктор БОГОРАД



Официант ачуы чыгып:
– Әгәр дә сезгә бу ризык ошамаса, нигә анда казынасыз? Сездән соң аны кем ашар?!

Бүген супермаркетта минем күз алдымда бер ир сатып алган әйберләре өчен картасы белән түләде, ә сырага – акча белән. Гаиләдәге яшерен бухгалтерия шулдыр инде.

– Җылылык өчен һәм суга квитанция килде.
– Шуннан нәрсә булган?
– Мине шәһәр мунчасы белән бутамадылар микән дип йөрим.

– Дустым, тыңла әле! Бу кәләш эзләвеңне никадәр озакка сузсаң, шулкадәр маҗаралы булырга мөмкин хатыныңның язмышы!

"Поворотник"ларын кабызмаганнарның Киркоровтан шактый зур аермалыгы бар – алар җырлый белмиләр.

Күп очракта, ирләргә карап, русча болай диләр: "Мужчина в самом соку!" Ягъни мәсәлән, безнеңчә: "Менә ичмасам егет!" – дип әйтеп куялар. Монда ир-атлар артыннан "Соковыжималка"лар ау кора.

Тиешле урынга куелмаган машинаны эвакуатор алып китү белән аның урынына икенче машина килеп баса. Һәм машина йөртүче тиз генә машинасыннан чыгып, эвакуатор шофёрыннан сорый:
– Штраф-стоянкага һәм кире әйләнеп кайтканчыга кадәр нихәтле вакыт кирәк?

Игътибарга лаек – эчүчелеккә каршы депутатлар тарафыннан каралган законнар барысы да иртәнге утырышта кабул ителгән.

– Доктор, миндә грипп, миңа нинди киңәш бирәсез?
– Миннән читкәрәк китегезче!

Абау!

КИРЕ ПРОЦЕСС

Татарстан шәһәрләрендә коммуналь челтәрләрнең искерүе инде сүз белән генә аңлатырлык түгел. Канализация һәм суүткәргечләр Казанда 73 процентка тузган, Түбән Камада – 70 процентка, чагыштырмача яшь Чаллыда – 54 кә. Бу хәлне инде озак еллар буе үзгәртеп булмый. Аларны сизелерлек дәрәҗәдә яңарту өчен ел саен челтәрләрнең кимендә 6 процентын алыштырып торырга кирәк, әмма башкалада да бу сан ике процентка җитми. Бу проблеманы хәл итәр өчен республикага 200–300 миллиард сум кирәк, ә акчаны каян табарга – монысы әлегә билгесез.

ФЕРМЕРЛЫК СОРАУ АСТЫНДА

Узган ел нәтиҗәләре буенча, ябылган фермер хуҗалыкларының саны ачылганнары белән чагыштырганның саны дүрт тапкыр артыграк булып чыккан. Эшчәнлекләрен 148 фермер тәмамлаган булса, бары тик 38 яңа хуҗалык ачылган. Авыл хуҗалыгы министрлыгында бу хәл борчу тудырган, чөнки 2023 ел эчендә җирле фермерлар 30 миллиард сумлык продукция җитештергән булганнар. Хәзер кешеләрнең җирдә нигә эшләргә теләмәвенең сәбәбен ачыкларга тырышачаклар.


БЕР-БЕРСЕ ӨСТЕНДӘ

Питрәч районының Богородское урта мәктәбе укучылары чын мәгънәсендә бер-берсенең өстендә утыралар дип әйтергә була. 250 балага дип төзелгән бинада 455 укучы белем ала. Ә күпсанлы яңа торак комплекслары төзелеп тору сәбәпле, кеше саны бара. Тыгынлыктан башка да, укучылар өчен шартларны шәптән дип әйтеп булмый: уку бүлмәләрендә канализация исе аңкып тора, стеналарда күгәрек таплары, бәдрәфләр кабинкалар белән җиһазланмаган, ишегалдында спорт мәйданчыгы юк. Роспотребнадзор санитар нормаларын тәртипкә китерү таләбе белән мәктәпкә һәм район Башкарма комитетына дәгъва белдергән. Болар тормышка ничек ашырылыр, әлегә билгеле түгел – генплан буенча яңа мәктәп төзү бары тик 2031 елда гына каралган.

ЯЛГАНЧЫ "ИР"

Казанда «бер сәгатьлек ир" ел буе үзен ялланган хатыннарны алдап йөргән. Эшмәкәр, йорт техникасы ремонтлауга килешенү төзеп, аванс алган, әмма вазыйфаларын үтәмәгән. Ул моны башта детальгә заказ ясау белән аңлаткан, аннары деталь килгән арада аның бәясе күтәрелгән дигән, ә соңрак, гомумән, телефонын алмый башлаган. Үз ирең дә үтенечне бер әйтеп кенә башкармый бит, дип, ханымнар башта түзгәннәр. Ниһаять, түземнәре шартлап, хатыннар барысы да бер "сәгатьлек иргә" полициягә шикаять яза башлаганнар.

Анастасия ВАСИЛЬЕВА



Александр ШУЛЬПИНОВ



Пенсия

Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА

Озак еллар эшләп, ниһаять, Гөлчәчәк пенсия яшенә җитте. Беренче пенсиясен кулына алу белән үк кәефе кителде. Шулай булмыйча, гомере буе эшлә дә, чеметеп кенә акча бирсеннәр әле.

– Әй Алла, нәрсә инде бу? – дип борчылды Гөлчәчәк.

– Карчык, кайгырма, гомер итәргә икебезнең пенсиябез җитәр. Ничек тә яшәрбез, – дип тынычландырмак булды ире.

Анысы шулай, дөрес. Ләкин барыбер тынычлыгы югалды Гөлчәчәкнең. Көне-төне башыннан чыкмый. Кибеткә керсә дә, уенда – шул.

– Менә, пенсиям күбрәк булса, тагын бу әйберне, әнә тегесен дә алырга булыр иде, – дип куйгалаганнары күп булды.

Күршеләре белән дә гел шул турыда сөйләшә. Инде барысын да аптыратып бетергәч, аны күрү белән барысы да өйләренә кача башладылар.

Соңгы вакытта:

– Хәзер телефон жуликлары күбәеп китте. Билгесез номерлардан шалтыраталар, җавап бирә башласаң, телефон аркылы акчаны урлыйлар икән, – дип әйткән иде бер күршесе.

– Минем урларлык нәрсәм юк шул. Күп акчалылар курыксын, – дип җавап биргән иде ул аңа.

Әмма барыбер күңеленә шик керде. Кайчагында Гөлчәчәккә дә шалтыраткалыйлар бит.

– Моннан соң шалтыратучылар булса, берсенә дә җавап бирмим, – дип, кискен карар куйды ул үзенә.

Вакыт үтә торгач, Гөлчәчәк тынычланды. Ләкин көтмәгәндә генә аның телефонына шалтыратулар ешая башлады. Көне-төне борчыйлар. Номерлары билгесез. Җавап биреп карый, трубканың икенче ягында дәшмиләр. Йә: "Әлү, сез мине ишетәсезме?" – дип сорап куялар.

"Бу караклар миңа да килеп җиткән инде. Барлы-юклы акчаны карт кешедән урламакчы булалар", – дип ачуы чыкты Гөлчәчәкнең.

Инде көннәрнең берендә тагын шалтыраталар моңа. Ул, түземлеге бетеп:

– Нәрсә, минем акчаны урламакчы буласызмы? Барлы-юклы пенсиям кирәк булдымы сезгә? Нинди акча булсын миндә? Гомерем буе эшләп күпме генә пенсия алам!

Җавап тавышы тынып торды һәм:

– Апа, гафу ит, – дигән ир кеше тавышы ишетелде. – Синең номерны моннан соң блокировкага куябыз. Без бит мохтаҗ кешеләрне таламыйбыз. Шалтыратучылар булмас. Акчаңа тимәсләр. Алай да, әйт, бәлки, сиңа ярдәм кирәктер?

Каушабрак калган Гөлчәчәк бераздан батыраеп:

– Шалтыратуларыгыз туктаса, шул зур ярдәм булыр... – дигән булды. – Менә бит, акчаң күп булмаса тынычрак яшисең икән. Урлыйлар дип кайгырып утырасы юк. Моннан соң зарланып та йөрмәм. Булганына шөкер!

Никифор ТУКМАЧЁВ

• • •

Бәйрәмнәр гел артып тора,
Һәр бәйрәм безгә шатлык.
Берләшсәк – Бердәмлек көне,
Таралышсак – Азатлык.
Җырлыйбыз да, биибез дә,
Бәйрәм итә беләбез.
Бәйрәмнәрдән исән чыксак,
Эшләп кенә үлмәбез.

ЮЛЛАР

Артка борчылып булса да,
Алга барган көнебез.
Коммунага булмаса да,
Юллар салган көнебез.
Мәскәү–Казан юлларында
Чаба алырбыз микән?
Чапканнарны куллар болгап
Озатып калырбыз микән?
Ул юллар Кытайга кадәр
Барып җитәчәк, имеш,
Түбән Каманы әйләнеп,
Узып китәчәк, имеш.
Кытайны барып күрергә
Бер җай табылыр әле.
Яшьлеккә кайтара торган
Юл да салыныр әле.
Бәхет безгә үзе килә,
Инде бәхет юлдашым.
Коммунизм дигәннәре
Бәлки инде юлдадыр.
Гаҗәп түгел оҗмахка да
Юл салына башласа.
Бу дөньяда юньле тормыш
Күреп булмас башкача.

Валентин ДУБИНИН



ТИШЕК КӨПЧӘК

ЮЛ ЧИТЕННӘН ХӘБӘРЛӘР

ҮЗ КЕСӘҢНӘН

Әгәр дә депутатлар үзебезнең илдә эшләнгән машиналарга күчеп утырмаса, Дәүләт Думасы аларга бензинга тотылган акчаны кайтармаячак. Иномаркада йөрүчеләргә ягулык өчен үз кесәләреннән түләргә туры киләчәк. Бөтен регионнарның хакимиятләре 2024 елдан депутатларга бары тик Россиядә җитештерелгән автотранспорттан гына файдаланырга кирәклеге турында мәгълүматны җиткерделәр инде. Владимир Путин да эшкәртү сәнәгате җитәкчеләре белән очрашуында бөтен Россия чиновниклары Россиядә эшләнгән автомобильләрдә йөрергә тиешлеген ассызыклап үтте.

БӘЯСЕНӘ КАРАП ТОРМЫЙБЫЗ

Татарстанлылар юллардагы комсыз машина йөртүчеләргә зарланалар. Чүпрәле районында бердәнбер транспорт чарасы булып такси калган. Аларның йөртүчеләре бәяләрне чамасыз күтәрәләр. Элек Казанга кадәр 650 сумга автобус йөргән булса, хәзер ул йөрүдән туктады. Ә «попутка»лар башкалага кадәр 900 сум сорыйлар. «Шәһәргә барырга бик кирәк булганда, кырып-себереп булса да җыеп барырга туры килә, – дип сөйлиләр авылда яшәүчеләр. Чүпрәледән Шатрашан авылына кадәр 550 сум түләргә туры килә, Чәкегә – 450 сум. Ә аларның арасы бары тик 20–25 чакрым гына».

ИСЕРЕК МАШИНА ЙӨРТҮЧЕ

27 яшьлек Чиләбе егете, аның исерек килеш машина йөртүе өчен беркетмә төзегән арада, гаишникларның машинасына утырып качкан. Ул, атна ахыры җитүгә бик шатланып, чамасыннан артык хәмер йоткан һәм шул килеш руль артына утырган. Ләкин ерак китә алмаган – парковкада торган берничә машинаны яньчегән. Урынга инспекторлар килеп җиткән һәм аны үзләренең машиналарына утыртып куйганнар, ләкин кулларын бәйләргә онытканнар. Тоткарланган исерек егет югалып калмаган: руль артына күчеп утырган һәм кузгалып киткән.


ЛИКЁРЛЫ КӘНФИТ СӨЮЧЕ

Түмән өлкәсенең Уват авылында юл инспекторлары исерек машина йөртүчене туктатканнар. Ул үзенең күтәренке күңелен... ярты кило ликёрлы кәнфит ашавы белән аңлаткан. Бу аңлатманы гаишниклар елмаю белән кабул иткәннәр, ә алкотестер аның канында алкоголь булуын күрсәткән. Өстәвенә, аның беркайчан да правасы булмаган икән. Кәнфит сөючегә карата административ протокол төзелгән, машина махсус стоянкага озатылган.

Михаил ЛАРИЧЕВ



Валентин ДУБИНИН



Игорь КИЙКО






Сәяси карикатура конкурсыннан рәсемнәр

Алексей МАМАЕВ (Казан)



Валерий ТАРАСЕНКО (Псков)



Андрей ЗАВГОРОДНИЙ (Санкт-Петербург)



Александр МОЛОТКОВ

ТИШЕК ТҮБӘ

Асия Исламовна, язның беренче яңгырына ничек кенә сөенмәсен, барыбер идарә компаниясенә шикаять язып барырга мәҗбүр булды.

– Нәрсә сезгә, апакай? – дип каршылады аны начальнигы, хөрмәт белән.

– Менә, җаныкаем, түбәбез тишелгән ахрысы, башыма тамчы тама. Мин соңгы катта яшим... – дип башлады ул сүзен, үтенечле итеп.

– Әйе шул, түбәне ямарга кирәк, әбизәтельне! – диде аңа җавапка начальник, татарчарак. – Бу хайваннар түбә карын көрәгәндә бөтен шиферны тишеп бетергәннәр...

– Менә шуның өчен килдем дә инде мин, - дип әйтеп куйды апакай.

Ләкин начальник, бу мәсьәләдән читкәрәк тайпылып, мондый сорау әйтеп ташлады:

– Компьютерыгыздан карагыз әле, йортыгызга күпме акча күчерелгән капиталь ремонтка?

– Мин компьютер белән эш итә белмим, акчаны бит һәрвакыт вакытында түлибез.

– Әйе, – диде начальник, – әлеге мәсьәләдә безнең кыенлыклар күп.

– Ә нәрсә булган? – дип сорарга мәҗбүр ителде апакай.

– Нәрсә телевизор карамыйсызмы әллә? Көньяк-көнчыгыш Замбуриндә ниләр барганын белмисезме? Валюта курс буенча югарыга сикергән, борча дустан курыккан кебек.

– Ә миңа нәрсә, анда алай булуы? – дип куйды Асия Исламовна исе китмәгәндәй.

– Менә сез бернәрсә дә белмисез бу мәсьәләдә, ә безнең караш – гомумдәүләти. Без әлеге дәүләт белән сәүдә итәбез, түбә япкыч материаллар сатып алабыз. Хәзерге моментта әлеге гамәл безгә файдалы түгел, шуңа күрә калай-шифер җитешми.

– Ә син безнең түбәне яма.

– Әй сез, апакай, әйтеп тә карыйсыз! – дип башлады начальник бу сорауга җавабын, түшенке тавышы белән. – Мин икенче ай буе төннәрен йоклый алмыйм. Ишеттегезме, нинди җил-давыллар булып узды ил буйлап? Күп кешеләр бөтенләй түбәсез калды, ә сез нинди тишек турында зар куптарасыз? Караватыгызны тамчы таммый торган урынга күчерегез дә, рәхәтләнеп йоклагыз!

– Анысы дөрес, түбәбез үз урынында, миндә бит әле бәләкәй балалар, – апакай кулъяулыгын күзенә китерде.

– Менә монысы чын гражданлык позициясе! – диде начальник, мөрәҗәгать белән килгән апакайны озата-чыга. – Көтегез, төзәтербез, барысы да җайлансын, тынычлансын әле.

Асия Исламовна ерак китәргә өлгермәде, начальникның кесә телефоны телгә килде. Урынбасары икән:

– Ишеттегезме, кичә Хитров белән Толкунов бер машина шиферны егерме меңгә читкә сатканнар!

– Нәрсә? – дип акырып җибәрде начальник. – Ничек алар... Кабахәтләр... Монда түбә ябарга әйбер табалмыйбыз...

Ачуы басылып, тынычлангач, ул мобильнигын өстәлгә куйды да, кәнәфиенә утырды:

– Вәт бәдбәхетләр! Ә миңа бит биш мең дип әйттеләр...

Игорь КИЙКО





Михаил ЛАРИЧЕВ



Евгений ОБУХОВ

ТҮЛӘҮЛЕ КЛИНИКА

– Исәнмесез, доктор!

– Керегез, тыңлыйм.

– Карагыз әле, доктор, әгәр дә кичен ныгытып нәрсә булса да ашасагыз, төнлә менә бу төшегездә таяк тыккан кебек тоелмыймы, сару кайнау башланмыймы?

– Юк… Соңгы вакытларда андый хәлнең булганын хәтерләмим дә…

– Ә менә күбрәк аракы эчеп җибәрсәгез яки тозлаган балык ашаган чакта аягыгыз шешкәләмиме? Подагра, дим, буыннар сызламыймы?

– Тфү-тфү, күптән андый нәрсәләр белән шаярганым юк!

– Яхшы. Доктор, менә, мәсәлән, бакчагызда көрәк белән эшләгәндә йә хатыны-гызның әнисенә булышам, дип, чемоданын күтәрешкәнсездер. Аның әйткән берәр сүзеннән нервларыгыз… Кан басымыгыз күтәрелмиме?

– Булгалады, ләкин хәзер нормально…

– Кулларыгызны сузыгыз әле, доктор, бармакларыгызны тырпайтыгыз. Тырнакларыгызны һәм күзегезнең агын карамакчы идем…

– Туктагызчы! Сез нәрсә? Монда бит мин түгел, сез килдегез түләүле клиникага. Мин сездән сораштырырга тиеш… Регистратурада карта тутырдыгызмы?

– Юк, доктор, мин үзем. Карыйм: кабинетыгызга бернинди чират юк – кердем дә киттем.

– Ә сез кем соң?

– Мин – доктор. Нетрадицион медицинаныкы. Экстрадулкыннар белән дәвалыйм, сораштырып та һәм ерактан торып та. Сезнең, аңлавымча, сәламәтлегегез яхшы?

– Әйе, әйбәт! Бөтен яктан!

– Менә, күрәсезме! Минем методым файдалы тәэсир иткән! Ә кабинетыгыз түләүле хезмәт күрсәтә…

– Әлбәттә! Язылган бит.

– Бик шәп! Доктор, минем тулы превентив дистанцион стабилизация үткәрү хезмәтемә сездән йөз доллар. Сумнар белән түләсәгез дә ярый.

Илдар НӘФИЕВ



ГИППОКРАТ ШАЯРТУЛАРЫ

Пациентның хәлен килгән чактагыдан начаррак итми торган бердәнбер табиб – патологоанатом.

Пациентлар – табибларга документлар белән эшләргә комачаулап йөрүче бәйләнчек кешеләр.

Үзен табиб дип йөргән мошенникны аңлаешлы почерк буенча тотканнар.

Түләүле медицина өчен терелгән кеше – кармактан ычкынган балык кебек.

Шәхси клиникада төчкерүче пациентка «сәламәт булыгыз» дип әйтмиләр, ә «рәхәтләнеп төчкерегез», диләр.



Сергей ТРУХАЧЁВ



НАРКОМАРКЕТ

Үз бизнесын яңа дәрәҗәгә чыгару өчен, Санкт-Петербургта яшәүче хатын-кыз интернетта үзенең онлайн-кибетен булдырган, ә товарны танылган маркетплейс аша җибәргән. Тик аның товары үзенчәлекле булган – төрле вак-төякләргә яшеренгән тыелган матдәләр. Петербургның сортлау складында 123 наркотиклар тартмасы, ә эшмәкәрнең өендә тагын 57 коробка табылган. Сәүдә масштаблы алып барыла алучылар арасында Мәскәү, Псков, Казан, Краснодар халкы исәпләнә. Наркотик сатучыны фаш итәргә маркетплейсның сыйфатны контрольдә тотуның стандарт процедурасы ярдәм иткән.

ЙОКЫДА һӘМ ЧЫНЛЫКТА ОЧУ

Ил-76 самолеты Тверь өлкәсе өстендә адашкан. Ләкин бу пилот хатасы түгел. Бортны алып баручы диспетчер эш урынында йоклап киткән.Очучылар аның белән элемтәгә кергәч, ул йокы аралаш Ил-76 га башка шәһәргә очучы башка самолетның очу планын бәйләгән. Аннары кабат йоклаган. Йокы чүлмәгенең хезмәттәшләре, самолет вакытында җиргә төшмәгәч, һавадагы тәртипсезлекне күреп алалар. һава вакыйгасында беркем дә зыян күрмәгән, ахыр чиктә самолёт җиргә утырган, ә диспетчерның гаепләнүчеләр эскәмиясенә утырачагы бик ихтимал.

САК АСТЫНДАГЫ РОМАНТИК

Тверь өлкәсенең Осинники шәһәре кешесе хатынын шаккаттырырга булган! Артык күп хәмер эчеп, өенә кайтып барганда ферма янында ат күргән һәм аны үзе белән иярткән. Ак атка атланган принц кыяфәтендәге ир-ат бишенче катка менгән. Гаҗәпкә калган ат фатирда ике сәгатькә якын кунак булган. Аннары романтик аны үз урынына илтеп куйган. Уңышлы нәтиҗәгә карамастан, ир-атны вак хулиганлык өчен бер тәүлеккә кулга алганнар. Полиция хезмәткәрләренә өйгә башка ат алып кайтмаска һәм хәтта башка аракы эчмәскә ант иткән.

Игорь КИЙКО



Виктор ФЁДОРОВ



УРАЗАГА КЕРГӘН СӘРХУШ АВЫЗЫННАН

Фәнил ГЫЙЛӘҖЕВ

Ай буена диетага утырам мин бүгеннән:
Аракыга якын килмәм, сырага да үрелмәм!

Кыстамагыз – иснәмим дә, өндәмәгез – килешми!
Табыннарга чакырмагыз, кирәк түгел, юк, эчмим!

Бу ай узсын әле башта, калган ягын – карарбыз!
Аллаһ кушып, денгә килсәк, моннан соң да салмабыз!

Аллаһ кушып, денгә килсәм, бер шешәдәш ким булыр.
Тәүбәдән кайтмый яшәүләр – батырлыкка тиң булыр!

Сез, әлбәттә, вәсвәсәләп йөрерсез Шайтан кебек.
"Чәркә күтәрер саулыгын җуйган хаста", дип көлеп.

Сез эчәрсез бу айда да, эчми тормассыз, беләм.
Минем күңелгә дә шакып узарсыз берәм-берәм.

Тик фәтвасыз булыр бу эш, нык торырмын сүземдә!
Шулай дим дә, әйткәнемә чак ышанам үзем дә…


Шулай хәерлерәк, беләм! Бәлки, бу – соң өметтер!
Җаһиллекне, сәрхушлыкны, Раббым, Үзең оныттыр!

Раббым, Үзең ярлыкагыл, йол җанны көферлектән!
Насыйп ит ризыкланырга тик хәләл эчемлектән!

Раббым, Үзең нигъмәтләндер зәмзәм суларың белән!
Сакла хәрам хәмереңнән, кыйлма эчкече бирән!

Насыйп булса, уразаны, шиксез, тотып чыгармын.
Ураза беткәч, тәүбәмне бозмый ничек чыдармын?!

Александр АЛЁШИН



Валентин ДУБИНИН





Зөфәр ӘХМӘТҖАНОВ

МАНДАРИН ХАТИРӘСЕ

Бәләкәй чакта мандарин, апельсин дигән җимешләрнең барлыгын белсәк тә, үсеп җитеп, эшләп таба башлагач, беренче мәртәбә авыз итүләре бик соң булды. Тамак тук икән – без шат, бәхетле идек.

Шулай бервакыт әниемнең дусты Җамал әби колхоз базарыннан мандарин алып килеп сыйламакчы булган безне. Әмма мандарин дигән сүз башыннан чыгып киткән. Тел очында гына торса да, онытып аптырап торганда бер танышы килеп чыга. "Карале, дустым, теге чиртеп уйный торган музыка коралы ничек атала иде әле ул?" – дип сораган. Мандолина икәнен белгәч, мандарин исенә төшкән. Онытмас өчен, "мандолина, мандолина", дип кабатлап бара торгач, сатучы грузинга да бер кило мандолина, дип әйткән. Татар карчыгын аңлап, грузин мандарин үлчәп биргән. Безгә килгәч: "Мандалина алып килдем әле", – дип көлдергән иде шаян карчык. Шул ук көнне бажайның әтисе Наил абый да буфеттан мандарин әләктереп килгән. Өстәл тулы мандарин! Бәйрәм өстенә бәйрәм! Нык сыйландык ул кичне. Ул заманнарда кечкенә генә әйбергә дә куана, шатлана белә идек. Дөньяның ямен бизәргә мандарин гына сәбәп түгел икәнен яши-яши генә аңлыйсың икән. Шуңа да сагындыра акыллыларның шаяра белүләре.



– Безнеке кебек мастерны табу җиңел түгел...

Иван ХАНТИМЕРОВ, 1966 ел.


Илдар ӘХМӘДИЕВ, 1971 ел.




– Иртәгә капчыгын кайтарырга онытма – дәүләт милеге бит ул!

АПЕЛЬСИНГА ЧИРАТТА

Җитмешенче еллар азагында Горький урамында Горгаз эше буенча эшләп йөрим. "Беларусь" экскаваторында, кышкы салкын көн. Өстә майга катКан телогрейка. Проходной янындагы буфеттан кешеләр апельсин алып чыгалар. Миңа да бирмәсләр микән, дип, кереп чиратка бастым. Минем артка, бәхетемә булса кирәк, Ринат Таҗетдинов килеп басты. Өстендә яхшы тун, кулында портфель. Үзе ниндидер җыр көйлиме, әллә сөйлиме, аңлап бетермәдем. Ул арада мине чакырып чыгардылар. Кабат кергәндә чиратка тагын бер ун кеше өстәлгән иде инде. Артка килеп басуга, Ринат Таҗетдинов, мине шәйләп, үз алдына чакырып бастырды. Миңа уңайсыз инде, май, солярка исе килә бит! Мәңге онытасым юк аның хезмәт кешесен шулай зурлавын. Олы дәрәҗәдәге кеше вак мәсьәләдә дә Олы була икән шул.


Александр ЛЕВИТИН



Вячеслав ШИЛОВ

Валентин ДУБИНИН




• • •

Яз килде! Суык:
– Миңа китәргә кирәк.
Кар:
– Миңа да...
Асфальт:
– Мине көтегез әле!

• • •

Бер кыз ак атка атланып килгән принцны көткән-көткән дә... Ә почтальон ахырдан аңа пенсия китергән.

• • •

Әгәр дә сезне оттырышсыз лотерея уенына тартырга тырышалар икән, димәк, сез оттырмыйча китә алмыйсыз.

• • •

– Доктор, нәрсәгәдер минем күзләр начар күрә башлады – кибетләрдә очсыз продуктлар бөтенләй күзгә чалынмый.

• • •

Телеканаллар күбәйгән саен, карарлыклары кими бара.

• • •

Элегрәк хатын-кызлар ут капкан йортларга керә иделәр, ә хәзер алар янып ятучы тур-сәяхәтләргә ашкыналар.

• • •

– Син әле һаман кияүгә чыкмадыңмы?
– Әгәр гүзәл зат ир таба алмый икән, димәк, язмышы аны нинди дә булса әүлия өчен саклый.
– Тик бер нәрсәгә игътибар итәргә кирәк – саклану срогы чыга күрмәсен.

• • •

Элек светодиодның нәрсә икәнен болай итеп аңлаталар иде – ул бәләкәй генә радио детале – светлячок кебек ялтырый торган. Хәзер болай аңлаталар, светлячок – ул шундый бәләкәй генә бөҗәк – светодиод кебек яктылык сибә торган.

• • •

Хатыны:
– Ни өчен бөтен нәрсә мин теләгәнчә түгел?
Ире:
– Ә син нәрсә телисең?
– Белмим дә инде...

Виталий ПОДВИЦКИЙ





ИСЛӘР... ХИСЛӘР...

Кадерле "Чаян". Мәгълүм инде – күршеләрне сайлап алмыйлар. Менә безнең күрше дигәннәребез дә ООО "Кама бекон" дуңгыз комплексы булып чыкты. Нишләмәк кирәк, шул чучкалардан чыккан чыдап булмаслык "хуш ис" тирә-юньгә тарала – противогаз киеп йөрикмени инде? Шуңа күрәдер монда яшәүче кешеләр арасында авыручылар күп: башлары авырта, сарулары кайный һәм башка шул сәбәпкә бәйле чирләр. Аларның зарлануларына дуңгыз хуҗалыгында эшләүче түрәләрнең үз акланулары: фермаларны гел җилләтү техникасы җитешмәү, җитешкән очракта аны табигатькә, һавага таратмый калу мөмкинлеген чикли алмау. Шулай итмәгәндә, чучкаларның үлеп бетү куркынычы бар икән.

Бу бик тә актуаль мәсьәләне бары тик махсус фильтрлар булдыру гына чишә ала, диләр, ләкин дуңгызчылар үзләре генә моны хәл итә алмый – кыйммәтле конструкцияләр төзү мөһимлеге генә бу хәлне чишә алачагын әйтәләр. Штраф түләве очсызрак икән. Штраф – фильтр түгел, ис һаман аңкый.

Сосновый Бор, Комсомолец һәм Татарстан совхозында яшәүчеләр.

ТУКАЙ р-ны

ХӘЙЛӘКӘРЛӘР...

Хөрмәтле редакция! Коры Елгадан (Сухая Река) Соцгородка кадәр йөрүче 37а номерлы яңа автобус маршруты башта безне бик шатландырды. Чөнки элеккеге 37 нчесендә соңгы вакытта 18 автобус урынына 2 се генә йөри башлаган иде һәм аларның безгә кадәр йөрү аралыгы дүрт сәгатькә артты! Шатлыгыбыз юкка булган икән.

Шул иске 37 нче маршрутта – Коры Елгадан Ферма-2 гә бөтен шәһәр буйлап барырга була иде һәм теләсә нинди кирәк җирендә төшеп калу мөмкинчелеге дә бар иде. Хәзер инде әлеге эксперимент буенча яңа маршрут килеп чыкты – ике мәртәбә кыскарак һәм... шул ук 2 автобус белән. Аларны көтеп алу вакыты бераз кыскарды, ләкин эшеңә яки йомышыңны башкарырга берничә транспортка күчеп утырырга кирәк. Әгәр дә шәһәрләрдә шәһәр транспорт системасы нығытып уйланылган булса, алынган билет күпмедер вакытка исәпләнсә, күченеп йөр рәхәтләнеп, Казанда бит ул алай түгел, һәр автобуска утыру түләүле. Туракла маршрутларны, күпме телисең, селкетеп йөр пассажирларын! Шунысы ап-ачык: 37а эксперименты халык өчен эшләнмәгән. Менә шуны уйлап чыгаручылар таный микән ялгышларын?

Коры Елга бистәсендә яшәүчеләр.

КАЗАН





Кем булган булыр иде ул
Әгәр дә язучы булмаса?
Мөгаен, прокурор булган
Булыр иде телен тыялса...

Кем булган булыр иде ул
Әгәр дә кыз булып тумаса?
Болай да әүлия кебек
Йөри бит инде лабаса!

Хөрмәт белән,

Алмаз ХӘМЗИН

ТАВЫК. ТҮТӘЙ. ӘТӘЧ. КҮКӘЙ.

Юк, юк! Әллә ни уйламагыз тагы, никакуй сәясәт. Сүз армиягә киткән әтәчләргә үпкәләп, йомырка салудан туктаган тавыклар хакында, җәмәгать. Чөнки күкәй мәсьәләсе, тавыклар күкәй салып торганда килеп чымый бит.

Үзебездән гел артып торган, ягъни товарга әйләнеп, базарга чыгарырга да калган тавык күкәе кинәт кенә юк булсын инде. Бездә җир күп, үлән-комы да җитәрлек, тавык салып торса, күкәй авыл кешесенә дә, шәһәренә дә җитә иде бит. Ә монда, Төркиядән кайтара башлаганнар диме? Адәм тәганәсе генәм лә! Димәк, әтәчләр, тавыкларны тыңламыйча, барыбер дә армиягә киткәннәр инде. Ну, җәмәгать, хатын-кызны аны үпкәләтү, гомумән, зур гөнаһ бит. Аны иркәләп кенә тотарга кирәк. Юкса...

Ярый, күкәен Төркиядән дә кайтардылар ди, ул хатыннарны үпкәләтсәң, алар армиягә барырга тиешле әтәч малайларын да тапмаска мужытлар ич.

Карале, тавык күкәе бик тиз ватылучан да ич әле ул. Аны Төркиядән ничекләр генә, нинди транспорт белән, дальнобойщикларга төяпме, поезд вагоннарындамы, әллә очкычлар белән кайтарырлар икән? Тавыкның күкәе дә хатын-кыз күңеле кебек тиз ualучан бит ул. Ә ватылып, бозылып та өлгерсә, нинди исләр чыгасын беләсез.

Поезд белән кайтарсалар... Өстәвенә, салкын кыш бит әле. Ну поезд вагоннарында суыткычлар була дигәнен ишеткәнем бар. Башта туңдырып, аннан сатып алучыга сиздермичә генә эретеп, бозып бетермәсәләр.

Юктыр, поезд белән ташып тормаслардыр. Самолёт тиз йөри, күкәй туңып өлгермәс.

Ярый, безотходный производство булмый дип уйласак, күпмедер күкәй безнең кибетләргә кадәр килеп тә җитте ди. Бәясе, бәясе нинди булыр соң? Күпме торыр ул төрек күкәе? Чөнки юл чыгымнары ифрат җыела бит.

Билет хакы дигәндәй... Ә чик сызыгын чыкканда пошлина түлиләр бит әле. Анысы күпме икән? Очсыз була алмый инде безнең ишегалдында тизәк типкән тавыкларныкыннан.

Шулай да төрек күкәен татып карыйсы килә, җәмәгать. Юк, мин ирләр турында сөйләмим, оятсыз дияргә бик ашыкмагыз...

Ярар, хәере белән кайтсыннар инде. Күкәй хакы күккә күтәрелгәч, үзебезнекеләр дә алтын сыман тоела башлаган иде инде.

Кызым әйтә: "Әни, күкәй күкәйдер инде ул, үз урынын табар", – ди.

Ул күкәйле ризыкны кайсы илдән килгән бәрәңге беләнме, яшелчә-җимеш янында табынга бирергәдер?

Кызым тыңлап торды да, тагын әйтеп куйды: "Кайгырма, әни, андагы тавыклар бездәге тавыкларныкы кебек крупный түгел, күкәйләре дә сандугач күкәйләре кадәр генәдер".

Шулай булса, хакы, бәясе? – дим.

Шаркылдап көлә юньсез кыз: "Күкәй, күкәй хакыдыр инде", – ди.

Үзебезнең чуаркайлар, ап-аккайлар җырлый-җырлый салган күкәйләрне авыз тутырып ашар идем, коймак-тәбикмәкләр ясар идем... Яңа елга салатлар, бавырсак, чәкчәк, гөбәдия, кыстыбый... Кара инде, күкәй кысылмаган бер ярык та юк икән безнең аш-су дөньясында...

Ни генә дисәгез дә, күкәй кирәк, җәмәгать. Хуҗабикәләр нинди илдән, нинди төстә, нинди зурлыкта булса да, тизрәк камырга кыстыру ягын карарлар. Күкәйнең дә милләте-фәләне юктыр Рәсәйгә кайтса. Әнә бит Хәмзәев әйтеп тора: Рәсәйдә бар милләтләр дә хәзер рус, ди. Их бу турыда да без үскәндә бер җыр бар иде, киез колак, яхшырак тыңламаганмын. Без үскәндә, өй саен бөтен нәрсәне сыдырып алып бара иделәр: ит, май, йон, тире, күкәй.

Ул чакта да күпчелек өйләр ир-атсыз, теге бөек сугыш кырларында ятып калганнар. Ашарга, булса, сепарат сөтеннән оетылган катык та, бәрәңге инде. Язга чыкканда сыерлары күтәрәмгә, үзләре куләгәгә калганнар аз булмады ул елларда. Бүгенге кебек Төркиядән түгел, тавык артыннан төшкәнне көтеп кенә тора иде әнкәй дә. Бүген ике күкәй булса, бәрәңге якмасы – шәнгә өстенә күкәй дә ягыла бит... Ни дисәң дә, күкәйле шәнгә күкәйле инде ул, җәмәгать.

Теге вакытта армиягә бармыйм, дип киреләнгән әтәчләр дә, әтәчләренә үпкәләгән тавыклар да бакыйлыкка күчеп беттеләр инде. Хәзер тавыклар да хәрби кием киеп ала, чөнки тигез хокуклылык, тигезлек булырга тиеш ир-ат белән хатын-кызлар арасында да. Түлке ир-атның күкәй салмавы, бала тапмавы бар тигезлекне боза да куя. Юкса хатын-кыз ир-ат эшли торган бар эшләрне дә эшли ала: бораулаучы, каравылчы, күмер кисүче, космонавт, төз атучы, күз атучы... Тфү-тфү! Тагы кешеләргә кучтем бугай. Тик күч-күчмә, безнең ирләр слабаклар инде. Бер әтәч кетәклектәге 20–30 тавыкны күзенә карата, табындыра үзенә. Ә ир дигәнең бер хатынына да хуҗа булалмый, валлаһи!

Дөньяларның бозылуы гел шул күкәйдән башлана дисәм дә, хата булмас. Юк, юк, күкәй җитмәүдән икән. Әнә шул килеп туган күкәй кытлыгы башларымны нинди генә уйларга салмады, җәмәгать: без үзебезгә күкәй дә булдыра алмыйбызмыни инде хәзер?

Дамир БӘДРИЕВ

АМЁБА

Җәмәгать, хатын-кызның ир-ат кабыргасыннан яралтылганлыгын беләбез. Ир заты ничек барлыкка килгән икән соң?

Уйлап-уйлап йөрдем дә, җавабын таптым мин моның. Кодрәт иясе ир кешенең сынын ясарга үзенең яшь ярдәмчеләренә кушкан булырга тиеш. Яшь-җилкенчәк эшне җиренә җиткереп башкармый бит инде ул. Болар, шаяра-көлә дигәндәй, елга ярындагы кызыл балчыктан ир затының сынын ясаганнар. Баш эченә ми салып калдырыр вакыт җиткәч, җиде кат күкләрдәге складтан баш мие алып төшәргә иренгәннәр. Елга төбендә яткан 1 тиен зурлыгындагы амёбаны күргәннәр дә, шуны дөньялыкта ир заты булачак сынның баш эченә тыгып калдырганнар. Игътибар итсәгез, ир-ат бөтен холыкфигыле белән амёбаны кабатлый. Мәгълүм булганча, амёба бер күзәнәкле, шулкадәр дә ялкау һәм битараф организм. Ул 1 минутка көчкә-көчкә 0,2 миллиметр ара уза. Ир заты да артыннан тибеп җибәрмәсәң кузгала алмый, бер эш рәтен дә белми. Ләкин бер эшне яхшы белә: «ашарга кайчан әзер була?» дип кычкырырга оста. Ашый да йоклый. Йоклаган чагында инфузория килеп төрткәли моны. Инфузориясе дә бер күзәнәкле миңгерәү шул. Амёба әкрен генә уратып-кочаклап ала инфузорияне. Кочаклашкач үрчеп китәләрдер, дип ялгыш нәтиҗә чыгара күрмәгез. Амёба үрчү турында уйламый да, әйтәм бит, йоклый.


Кытайда, Һиндстанда, Урта Азиядәге башка илләрдә «Демография» дигән программа гомумән дә юк. Ана капиталын хатын-кызларга түгел, ир-атларга бирә башларга кирәк, дип уйлап торам әле. Безнең ир-ат амёбалар бераз селкенә башламас идеме икән, дим. Тик, шикләнеп тә куйдым, чөнки амёбаның акчаны эчеп бетерүе ихтимал.

Кайбер амёбалар дулкынга эләгеп яки инфузориясе булышлыгында югарыга күтәрелү бәхетенә ирешә. Югарыга күтәрелгән амёба үзенең бер күзәнәкле организм икәнлеген онытa, мин-минлек чиреннән саташа башлый. Елга төбендә калган кардәшләре аңа инде микроблар булып кына тоела.

Хәрәкәтчәнрәк инфузориянең амёба кочагыннан чыгып китүе өчен әллә ни кадәр вакыты бар. Ләкин ул чыкмый, амёбаны котыртып-хисләндереп һаман төртенә. Гаилә корган кешеләр белә инде төртешүнең ни белән тәмамланасын. Иң мөһиме – амёбага «ник кочакладым?», ә инфузориягә «ник төртендем?» дип үкенергә калмасын. Кавышып яратышып кочаклашулары гомерлек булсын.

Кайбер инфузорияләр төртенгәләп йөрүне генә хуп күрә, амёба кочагында яшәүне кирәк санамый. Хәер, еллар узгач, ялгышканлыкларын аңлыйлар, ләкин соң була инде. Инфузория матур башмакчаларын киеп, очрашуларга бик барыр иде дә, тик инде чакыручы, күз кысучы юк. Кечкенә инфузорочкалар үсеп җиткән. Инфузория бикәләр, гафу итегез, извините, аймсорри!

Амёбаның акрын кыймылдаганын әйттем бит. Моның өстенә тәвәккәлсез дә бит әле ул. Инфузорияләре акыл биреп, үсендереп яки камчылап тормаса, амёбалар зур эшләргә дә тотынмый, авырып китсә, даруын да эчә белми хәтта. Баш миебез бер күзәнәкле амёба булса да, инфузорияләрне кадерләп һәм хөрмәтләп яшәргә тырышыйк. Чөнки инфузорияләрдән башка безнең эш харап.



Виктор БОГОРАД



ЧАЯН
САТИРА һӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ
1923 елдан чыга.
№ 4 (1941) апрель 2024

Баш редактор:
Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш рәссам: А. АЛЁШИН
Баш редактор урынбасары: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Үсеш бүлеге: П. СТАРОВЕРОВ
Редакторлар: Р. АБЗАЛОВ,
Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН
Сайт редакторы: Л. ӘХМӘТОВА
Корреспондент: Г. СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
420047, Татарстан Республикасы, Казан, Академическая урамы, 2
Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре агентлыгы ярдәмендә оештырылган.
Журнал Роскомнадзор идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты: ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.
«Журналга «Почта России» каталогы, йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша язылa алалар.

Язылу индекслары:
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).
Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» типографиясендә басылды.
420066, Татарстан Республикасы, Казан, Декабристлар ур., 2.
Чыгу көне: 01.04.2024 ел.
Тираж – 2118 Заказ А-0657
Редакциянең адресы: 420066, Татарстан Республикасы, Казан, Декабристлар ур., 2.
Белешмәләр өчен телефоннар: (843) 222-06-00, 222-05-54.
E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru
Бәясе ирекле
16+

Уйна да, уйла да!

МУЗЫКАНТ НӘҖИП ...

ЯЗУЧЫ ФАТИХ ...

БАЯНЧЫ ... КУРАМШИН

МИРСӘЙ ...

АЙЛЫ ... БИКТАҺИРОВ

МИНЕРАЛЬ СУ

ШӘРАБ

ТӨЗЕЛЕШТӘ ДӘ, КУХНЯДА ДА

ҮЛЧӘҮ

ГАЛИЯБАНУНЫҢ СӨЙГӘНЕ

НОТА

ТУКЫМА

НОТА

ПЫЛАУНЫҢ ТӨП ӨЛЕШЕ

ЗАТЛЫ ПЫЯЛА

ҖЫРЧЫ ТАВЫШЫ

ИРКӘЛӘҮ

ҖЫРЧЫ РАМИЛ ...

"ГҮЗӘЛЕМ ..." (Ч. АЙТМАТОВ)

ОЯТ

(-1) ЭПОХА

"ӘЛДЕРМЕШТӘН ..."

ШӘЙМИЕВНЕҢ ТУГАН АВЫЛЫ

(-2) ... КҮҢЕЛЕ ДАЛАДА

КӨНЬЯК ҖИМЕШЕ

"... ЧӘЧӘК АТА ИЛЕМ"

КЕЧКЕНӘ ТАРТМА

НОТА

"БЕЗНЕҢ ЮЛЛАР КҮӘ ..."

"ҺӘМ" ИСКЕЧӘ

... АРСЛАНОВ

1000 м

"... МИНЕ, КАЙТЫРМЫН"

(-2)

"... ЧӘЧӘКЛӘР"

... КҮҢЕЛ

"ЙӨРҮДӘН МӘҢГЕ ... БИЗМӘМ МИН"

ТУГАН ...

1 2 3 4 5 6 7 8 9 10 11 12 13 14 15 16

Ринат АБЗАЛОВ төзеде



1. Чын бәхет нинди була?

2. Ир белән хатын арасындагы матур яшәү алымы?

3. Урда белән хатынкызның кибетләргә чабуындагы аермалык нәрсәдә?

4. Нәрсә ул мандарин?

5. Гаилә бюджетындагы уртак җаваплылык нинди булырга тиеш?

6. Кием-салым өчен иң яхшы шкаф?

7. Бәхетле булуның рецепты?

ҖАВАПЛАР

1. Сезнең бар нәрсәгез дә җитеш, теләгәнегез дә үтәлгән һәм сез әле һаман иректе. 2. Хатыныгыз кайдан акча тапканыгызны сораштырмаганда, ә ирегез акчагыз кая киткәнен белмәгәндә. 3. Урдалылар нәрсә кирәген белгәннәр. 4. Яңа ел көнбагышы. 5. Ир керем турында кайгырта, ә хатын чыгымда җаваплы. 6. Урындык инсәсе. 7. Үткәннәреңә оялып утырмау, бүгенгесенә күңелең тыныч булу, киләчәгең өчен кайгырмау.

Сынамышларны Гүзәл **СӨНГАТУЛЛИНА** әзерләде.

Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда җыр исемен укыгыз. Журналыбызның 3 нче санында басылган чаянвордның тикшерү сүзе – **«МИН ГАРМУН БУЛЫР ИДЕМ»**

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:

Г. БАҺАВЕТДИНОВ (Чаллы),
С. ШӘЙХУЛЛА-ӘНӘЛЕ (Казан),
З. ЯРУЛЛИНА (Апас).

Җиңүчебез – Чаллыдан **Гали БАҺАВЕТДИНОВ!**

ЯЗГЫ ЕЛМАЮЛАР



Валерий ТАРАСЕНКО



Сергей КОКАРЕВ



Александр АЛЁШИН


Сергей ТРУХАЧЁВ


Виктор ФЁДОРОВ

